РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Карамалинского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 8,
Азнакаевский район, с.Вахит ,
423301,
тел./факс (885592)45-6-42
E-mail: Karam.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Вахит авыл җирлеге
башлыгы

Үзәк ур., 8нче йорт, Азнакай
районы, Вахит авылы, 423301
тел./факс (885592)45-6-42
E-mail: Karam.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«30» октябрь 2025 ел** **№ 3**

2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең Победа торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлеге Уставының 15.1 статьясы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең Победа торак пунктында теркәлгән 2025 елның 14 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта гражданнар җыенын үткәрергә.

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең Победа торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп -Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Башкарма комитетын;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты-2025 елның 14 ноябрендә 15.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр;

– гражданнар җыенын уздыру урыны- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Победа торак пункты, Үзәк урамы, 29 (Мәдәният йорты бинасы);

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
Сез "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең Победа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, 2 төркем инвалидлардан көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнарыннан тыш, 2026 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган

акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы?

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (энергияне саклый торган лампалар, электр товарлары, махсус җайланмалар һәм башка материаллар сатып алу һәм урнаштыру, яктырткычларны һәм урам яктырткычларын алмаштыру, урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү);

2) су белән тәэмин итү һәм су түгү системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Победа поселогы, Үзәк ур., 11 һәм 13, 18 йортлар адресы буенча күпфатирлы торак йортларның су түгү системаларын ремонтлау);

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татарстан урамында вак таш сатып алу, төяү, ташу, салу)

4) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны кышкы һәм җәйге тоту)

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан: Победа поселогы, Үзәк ур,2 мәгълүмат стендларында, урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык

Г.И. Әскәрова